*... Җәйге ял никадәр генә күңелле булса да, алда беренче сентябрь барлыгын да онытырга ярамый: яңа беренче сыйныф укучылары парта артына утыралар, яңа сабыйлар беренче тапкыр балалар бакчасына аяк басалар, былтыр башлангыч сыйныфта укыган балалар быел бишенче сыйныфка- "урта өлеш"кә күчәләр.*

*Бераз гына ямансу,шулай да, көтеп алынган Яңа уку елы килеп җитте. Яңа уку елы ул- дәрескә чакырып чыңлаучы көмеш кыңгырау чыңы, кызыклы дәресләр һәм күңелле тәнәфесләр...*

*Кадерле дусларым, сезне барыгызны да Яңа уку елы белән, Белем бәйрәме белән котлыйбыз! Яңа уку елы сезгә яңа дуслар, яңа уңышлар алып килсен.Тырышып укыгыз, әти-әниләрегез һәм укытучыларыгыз өчен мактаныч булыгыз.*

*Укытучылар коллеективы*

**Хөрмәтле укытучылар!**

*Сезне һөнәри бәйрәмегез—Белем бәйрәме, яңа уку елы башлану белән тәбрик итәбез. Авыр, катлаулы эшегездә зур уңышлар, гаиләгезгә иминлек, нык сәламәтлек, үзегез тәрбияләгән бала ларның игелеген күрүегезне телибез. Һәрвакыт шулай сабыр, олы йөрәкле булып калыгыз! Теләкләрегез, хыялларыгыз чынга ашсын! Җылы сүзләребезне, изге теләкләребезне шигъри юллар аша җиткерәсебез килә:*

*Ак кәгазьдәй сабый күңеленә*
*Язмышларны башлап яздыгыз,*
*Өмет тулы күпме күзләргә сез*
*Яшәү чаткылары салдыгыз.*
*Кайгыртып гел кеше кайгыларын*
*Безнең яңашәдә эшлисез.*
*Ходай сезгә озын гомер бирсен,*
*Рәхмәт Сезгә, чын-чын кеше Сез!*

*Укучылар комитеты*

# 1сентябрь
# белем бәйрәме

сентябрь/2017

**“Яшь көч” балалар оешмасы газетасы**



Сентябрь килде гөрләп,
Урамнар ямьләнделәр,
Сумка тотып балалар
Мәктәпкә юнәлделәр.

Класслар нурландылар
Балалар белән тулып,
Звонок яңгырады
Көчле һәм матур булып.

Керделәр классларга
Бар балалар сөенеп,
Һәр фәнне укыр алар
Чын күңелдән бирелеп.



Исәнме, мәктәп! Исәнме
Көзнең яфраклы юлы.
Саумы, беренче
сентябрь-
Өр-яңа уку елы.
Исәнме, көзге кояшның
Алтынсу тәүге нуры.
Гыйлем дөньясына илтер
Юлыбыз кебек туры.








**Көзге тантана яки**
**ИСӘНМЕ, СЕНТЯБРЬ!**

Менә тагын сентябрüгә кердек. Сентябрü диюгә, күңелгә рифмалы юллар килә:

Җәй үтте, көз җитте,
Көз безне үз итте...
Мин дә бер, син дә бер,
Исәнме, Сентябрь

Әйе, әле кичә генә ямüле, кояшлы җәй хозурында идек без. Ошбу җәй турында, җәйдә күргәннәребез, тәэсир-кичерешләребез хакында сөйләп бетерерлек кенә түгел, шулай бит Шагыйрü абый әйтмешли:

Җәй узмас, диеп,
Уйлаган идек:
Таңнан кичкәчә
Уйнаган идек.

Сизми калганбыз
Көз килгәнен дә,
Тәүге яфраклар
Өзелгәнен дә...

Әйе, әле кичә генә җәй иде. Бүген инде табигатüтә көз тантана итә. Көз тантанасы – офыклардан офыкларгача җәйрәп яткан басу- кырларда, алтынсу көшелләр белән тулы ындыр табакларында, тәрәзәләреннән яктылык сибелеп, җылылык бөркелеп торган өйләрдә, аң-белем нурлары өләшүче мәктәпләрдә, көз тантанасы -- өлкәннәрнең гамüле күзләрендә, балаларның көләч йөзләрендә, кыңгырауларның дәртле чыңнарында...

Кыңгырау чыңы дигәннән:

Көзнең килгәнен
Белмәс идек без,
Әле һаман да
Сизмәс идек без--

Кыңгырау чыңы
Искә төшерде:
Көзнең килүен
Шундук төшендек...

*Берәү гомере буе вакыт җиткералмый аптырый, берәү вакытны кая куярга белми интегә. Вакыт җитмәгәне гомер узганны сизми дә кала, тегесе озак яшәде сыман. Ә эшләренә карагандa— беренчесе озак яшәгән! Вакыт җиткерә алмый эшләгән кеше үзеннән соң да яши – кылган гамәлләрендә, эшләрендә яши.*

*Шәүкәт Галиев*

*Хәерле юлга!*

*Вакытыгызны әрәм үткәрмәгез.*
*Мәктәп елларының кадерен белегез!*